ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 542-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 542-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 19 апреле
№ 2435-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьягатүбәндәге эчтәлекле $7^3$ пункт өстәргә:

«$7^3$) портлардагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне (алга таба – елга порты объектлары) хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда күрсәтелгән йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унбишенче һәм уналтынча абзацлар өстәргә:

«Елга порты объекты хосусыйлаштырылган очракта, елга порты объектын аны «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^3$ статьясындагы 1 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән максатларга туры китереп файдалану йөкләмәләре белән чикләп тору хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга мөһим шарт буларак кертелергә тиеш, моңа Россия Федерациясе Эчке су транспорты кодексының 53 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртип буенча эчке су транспорты инфраструктурасы объектлары сыйфатында ихтыяҗ булмаган объектларга кертелгән елга порты объекты (алга таба – елга портының эчке су транспорты инфраструктурасы объекты сыйфатында ихтыяҗ булмаган объекты) керми.

Елга портының эчке су транспорты инфраструктурасы объекты сыйфатында ихтыяҗ булмаган объектлары «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне

хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм алымнар белән әлеге Федераль законның $30^3$ статьясында күрсәтелгән чикләп торуларны исәпкә алмыйча хосусыйлаштырылырга мөмкин.»;

б) унбишенче һәм уналтынчы абзацларны тиешенчә унҗиденче һәм унсигезенче абзацлар дип санарга;

3) 10 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «һәм мондый челтәрләр объектларын» сүзләреннән соң «, канәгатьләнерлек хәлдә булмаган елга порты объектларын» сүзләрен өстәргә;

б) алтынчы абзацта «челтәрләр объектларына» сүзләреннән соң «, канәгатьләнерлек хәлдә булмаган елга порты объектларына» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 26 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законның 20 һ 30.3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Эчке су юллары кодексының 3 һәм 53 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 27 ноябрендәге 557-ФЗ номерлы Федераль закон белән (ул рәсми басылып чыккан көненнән соң туксан көн узгач – 2024 елның 26 маенда үз көченә керә) «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга портлардагы канәгатьләнерлек хәлдә булмаган гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), төяп күчерү комплексларын һәм елга портларындагы башка мөлкәтне хосусыйлаштыру мөмкинлеге карала торган үзгәрешләр кертелде.

Аерым алганда, кертелгән үзгәрешләр нигезендә елга порталындагы канәгатьләнерлек булмаган хәлдәге объектларны сату конкурс буенча башкарыла һәм аларны хосусыйлаштыру үзенчәлекләре билгеләнә. Бу үзенчәлекләр, шул исәптән, елга порты объектын хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарның эчтәлегенә дә кагыла. Мондый карарда объектларны пассажирларга һәм судноларга хезмәт күрсәтү, йөк төяү, бушату, саклау һәм тапшыру, транспортның башка төрләре белән эшчәнлек максатларына туры китереп файдалану йөкләмәләре белән чикләп тору мөһим шарт буларак кертелергә тиеш. Шулай ук елга порты объектларын сату буенча конкурс шартларында аларны ремонтлау һәм башка эшләр уздыру да каралырга мөмкин.

Моннан тыш, елга порты объектларына карата чикләп торуларны үтәүне тикшереп тору турында нигезләмәләр кертелде. Елга порты объектын хосусыйлаштыру турындагы карарда билгеләнгән чикләп торуларны үтәүне тикшереп тору тәртибе дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, федераль законнардагы әлеге үзгәрешләрне «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына да кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының бүтән законнарын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан портлардагы гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), күчереп төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда билгеләнгән йөкләмәләрнең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгеләү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.